**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ ПР-226 22.10.2024 № ______

"Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының административ комиссиясе тарафыннан "Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы" муниципаль берәмлеге бюджетына салынган административ штрафлар түләү бурычын түләтүгә өметсез дип тану һәм исәптән чыгару турында карарлар кабул итү тәртибен раслау хакында" Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 27 августындагы ПР-205 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 маендагы 393 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 10 октябрендәге 1360 номерлы карары нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. "Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының административ комиссиясе тарафыннан "Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы" муниципаль берәмлеге бюджетына салынган административ штрафлар түләү бурычын түләтүгә өметсез дип тану һәм исәптән чыгару турында карарлар кабул итү тәртибен раслау хакында" 2018 елның 27 августындагы ПР-205 номерлы карарына (үзгәрешләр белән 2020 елның 07 августындагы № ПР-150, 2024 елның 06 сентябрендәге ПР-161) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. **III бүлектә:**

а) **«в» пунктчасында** "хисаплылыктан өземтә" сүзләрен "белешмә"сүзенә алмаштырырга.:

б) **«г» пунктчасында** "Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160_1 статьясы нигезендә билгеләнгән бюджетка түләүләр, алар буенча пенялар һәм штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү буенча бюджет керемнәре администраторы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Регламентында каралган"сүзләрен өстәргә.

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"гражданның судтан тыш банкротлыгы процедурасын тәмамлау турында банкротлык турында белешмәләрнең бердәм федераль реестрыннан белешмәләр булган документ.".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җапаплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.А.Ильясов